| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ КУГУНУРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КУНЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

« 12 » мая 2025 г. № 128

Балтач муниципаль районы Куныр авыл җирлеге Советының «Куныр авыл җирлеге башлыгы, Куныр авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең хезмәтенә түләү тәртибе турында»гы 2018 елның 25 декабрендәге 102 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (2023 елның 22 марта 72 нче номерлы, 2024 елның 17 июле 99 нчы номерлы, 2024 елның 30 октябре,106 нчы номерлы үзгәрешләр белән)

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары, муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 14 нче апреле 228 нче номерлы карары, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең контроль-хисап палатасы рәисенә, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәре, айлык һәм башка өстәмә түләүләр һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе күләмнәре турында» Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2018 елның 28 апрелендәге 127 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Советының 2025 елның 30 нчы апреле 315 нче номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Куныр авыл җирлеге Уставы нигезендә Балтач муниципаль районының Куныр авыл җирлеге Советы карар итте:

1.«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Куныр авыл җирлеге башлыгының, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Куныр авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең (алга таба - Карар) хезмәтенә түләү тәртибе турында» 2018 елның 25 нче декабрендәге 102 нчы номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Куныр авыл җирлеге советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 2 пунктындагы «13990» санын «15389» санына алмаштырырга;

1.2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Кунырр авыл җирлеге башлыгы хезмәтенә түләү Тәртибенең (1нче кушымта) 1 пунктында «19173» санын «23091» санына алмаштырырга.

1.3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Куныр авыл җирлеге башлыгы, Куныр авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең хезмәтенә түләү Тәртибенең 2 пунктында «14,12» санын «16,85» санына алмаштырырга.

1.4. Куныр авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру тәртибенең 6 пунктчасында «41 процент» сүзләрен «58 процент» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (www.baltasi.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар имза салынган көннән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Куныр авыл җирлеге башлыгы — Р.О.Егоров